ГЛАВА ДЫМ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Дым-Тамак, ул.Новая, д.4в, 423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Димтамак авылы, Яна урам, 4 в йорт,
423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz@tatar.ru

**Постановление** **Карар**
**№ 6** **30 ноябрь 2021 ел**

2022 елда Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегендәге
Тарлау торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы карарының 25.1, 56 санлы маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, 2019 елның 17 июлендә 7 санлы карары белән кабул ителгән Ютазы муниципаль районы «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14, 81 маддәләре нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 16 декабрендә 14.00 сәгатьтә Димтамак авыл җирлегенә керүче Тарлау торак пунктында Гафиятуллин урамы, 15 санлы йорт адресы буенча 2022 елда Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Тарлау торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Тарлау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган тормыш иптәшләре, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 550 (биш йөз илле) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- буаны чистарту;
- Тарлау торак пунктында зират территориясе коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);
- балалар мәйданчыгын коймалап алу өчен материаллар сатып алу (эшләр өчен килешү нигезендә түләү.

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Димтамак авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны Димтамак авыл җирлегендәге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http://jutaza.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында кабул ителгән көннән 5 көн эчендә бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көннән (халыкка җиткерелгән көннән) үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Димтамак авыл җирлеге башлыгы Җ.Ә.Хөснетдинов